КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 декабрь г.Казань № 1245

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1141 нче; 2020 ел, 13 июль, 584 нче; 2021 ел, 31 май, 408 нче; 2022 ел, 11 февраль, 114 нче; 2022 ел, 10 июнь, 546 нчы; 2022 ел, 16 декабрь, 1354 нче; 2023 ел, 2 май, 549 нчы; 2023 ел, 30 май, 660 нчы; 2023 ел, 22 сентябрь, 1180 нче; 2024 ел, 6 август, 626 нчы; 2024 ел, 27 сентябрь, 839 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыру чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыру чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин